**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КИЛЬДЮШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИЛДЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422387, с. Кильдюшево, ул.Молодёжная, 22

422387, с. Кильдюшево, ул.Молодёжная, 22

тел. (84373) 5-22-66,e-mail: Kld.Tet@tatar.ru

ОГРН 1061672018264, ИНН/КПП 1638005065/163801001

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**25 .10. 2023** **№ 6**

**Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлегенең җәмәгать зиратлары территориясендә гаилә (ыру) җирләүләрен оештыру тәртибен раслау турында**

«Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Килдеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлегенең җәмәгать зиратлары территориясендә гаилә (ыру) җирләүләрен оештыруның кушымталы тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Килдеш авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмати стендларда игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга http://tetushi.tatarstan.ru/ һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында " (PRAVO.TATARSTAN.RU)урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** **В.С. Исаев**